| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.09.2024 п.г.т.Алексеевское № 370

**Башкарма комитетның 27.12.2019 ел, № 589 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Күпбалалы гаиләләргә өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү максатларында, «Татарстан Республикасында күпбалалы гаиләләргә өстәмә социаль ярдәм чаралары турында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1992 елның 28 декабрендәге 708 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында»Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 6 июнендәге 410 номерлы карары нигезендә

**карар бирәм:**

1. Башкарма комитетның 27.12.2019 ел, № 589 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» карарына 2 нче кушымтаның 2.2 пунктына үзгәрешләр кертергә түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында ата-аналар түләве күләме мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында балаларны карау һәм карап тору чыгымнарын үз эченә ала.

Катнаш һәм савыктыру юнәлешендәге төркемнәргә йөрүче балалар өчен ата-ана түләве күләме гомуми үсеш юнәлешендәге төркемнәргә йөрүче балалар өчен ата-ана түләве дәрәҗәсендә билгеләнә.

Күп балалы гаиләләр өчен социаль ярдәм чарасы – ата-аналар түләве күләмен 50 процентка киметү билгеләнә.

Күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары өлкән бала 18 яшькә яисә 23 яшькә җиткәнче, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада көндезге бүлектә белем алу шарты белән гамәлгә ашырыла».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е.А. Хәмзинага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе**
**вазыйфаларын башкаручы** **О.Н. Леденцов**